СОВЕТ НУРИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НӨНӘГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь 2022 ел №56

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым жыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә үзара салым жыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турындагы Нөнәгәр авыл җирлеге Советының 11.04.2014 елгы № 86нчы карары белән расланган ( 14.11.2017 ел, №56, 20.11.2019 ел, №120 редакциясендә) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

"Җирле референдумда кабул ителгән карар нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, 18 яшькә җиткән барлык гражданнарга да үзара салым акчаларын түләүне өч ай эчендә башкарырга, яшәү урыны җирлек чикләрендә булган,җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән:1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, балачактан инвалидлар, 90 яшьтән өлкәнрәкләр, ятучы авыруларалар, Россия Федерациясе кораллы кечләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан башка; үзара салым суммасының 50 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән тыл хезмәтчәннәре, сугыш чоры балалары, ялгыз аналар, 18 яшькә кадәр балалары булган тол хатыннар, урта һәм югары уку йортларында көндезге формада белем алучы студентлардан башка җирлек башкарма комитетының хәбәрнамәсе нигезендә җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә ала.

2.Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны районның baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Нөнәгәр авыл җирлеге
башлыгы А.З.Әхмәтханов